КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 19 апрель г.Казань № 268

Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формаларын раслау хакында

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгәннәрне расларга:

җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын;

җирле үзидарә органнары тарафыннан торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп

торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисап формасын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшерүен һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен башкару турындагы хисап формасын раслау хакында» 2011 ел, 20 гыйнвар, 29 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 19 апрель, 268 нче
карары белән расланды

Форма

______________________________

Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы
хисап

________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
_______елның ______ кварталы

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Күрсәткечнең мәгънәсе |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Муниципаль берәмлек территориясендә өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп төзелә (төзи) торган күпфатирлы йортлар һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектлары (алга таба – объектлар) саны | |
| 2. | Закон бозулар ачыкланган объектлар саны | |
| 3. | Муниципаль берәмлек территориясендә өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп төзелә торган объектлар турында мәгълүматлар | әлеге хисапка кушымта нигезендә |
| 4. | Йорт төзүченең һәм проект декларациясенең «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелештә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 214-ФЗ номерлы Федераль закон) 3 статьясындагы 2 өлеш, 20 һәм 21статьялары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бирелгән бәяләмәләр саны | |
| 5. | Йорт төзүченең һәм проект декларациясенең 214-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 өлеш, 20 һәм 21статьялары белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында бәяләмәләр бирүдән баш тартулар саны | |
| 6. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында йорт төзүчеләрнең квартал саен хисаплары турында» 2005 ел, 27 октябрь, 645 нче карары белән билгеләнгән форма буенча квартал хисабын биргән йорт төзүчеләр саны | |
| 7. | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында йорт төзүчеләрнең квартал саен хисаплары турында» 2005 ел, 27 октябрь, 645 нче карары белән билгеләнгән форма буенча квартал хисабын бирмәгән төзүчеләр саны | |
| 8. | Муниципаль берәмлек территориясендә өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итә торган йорт төзүчеләр саны | |
| 9. | Суд карары белән бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип танылган йорт төзүчеләр саны | |
| 10. | Акчалары күпфатирлы йортларны төзүгә җәлеп ителгән һәм хокуклары бозылган зыян күргән гражданнар реестрына кертелгән гражданнар саны | |
| 11. | Өлешле төзелеш өлкәсендә билгеле булган закон бозулар саны | |
| 12. | 214-ФЗ номерлы Федераль законны бозу белән бәйле мөрәҗәгатьләр саны, шул исәптән:<br>гражданнардан;<br>юридик затлардан | |
| 13. | Өлешле төзелештә катнашучыларның законлы мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклый торган гаризалар белән җирле үзидарә органнары судка керткән мөрәҗәгатьләр саны | |
| 14. | Өлешле төзелештә катнашучылар файдасына канәгатьләндерелгән дәгъвалар саны | |
| 15. | Җинаять эше кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен мәҗбүри таләпләрне бозуның җинаять җаваплылыгына тартыла торган гамәл билгеләре булган фактлары ачыклану белән бәйле хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны | |
| 16. | Җинаять эше кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган бүтән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне бозуның җинаять җаваплылыгына тартыла торган гамәл билгеләре булган фактлары ачыклану белән бәйле җирле үзидарә органнары җибәргән материаллар буенча хокук саклау | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | органнары кузгаткан җинаять эшләре саны | |
| 17. | Җирле үзидарә органы тарафыннан йорт төзүчеләргә җибәрелгән закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр саны | |
| 18. | Җирле үзидарә органы тарафыннан йорт төзүчеләргә җибәрелгән закон бозуларны бетерү турындагы үтәлгән күрсәтмәләр саны | |
| 19. | Законнар белән билгеләнгән җаваплылыкка тартылган йорт төзүчеләр (аларның вазыйфаи затлары) саны | |
| 20. | Өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекне йорт төзүче тарафыннан гамәлгә ашыруны билгеле бер вакытка туктатып тору турындагы гариза белән җирле үзидарә органнары арбитраж судка керткән мөрәҗәгатьләр саны,<br>шул исәптән эшчәнлекләре билгеле бер вакытка туктатып торылган йорт төзүчеләр саны | |
| 21. | 214-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән очракларда, җирле үзидарә органнары тарафыннан арбитраж судка йорт төзүче оешманы бетерү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итү саны<br>шул исәптән суд карары нигезендә ябылган йорт төзүчеләр саны | |
| 22. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның $3^1$ статьясы белән билгеләнгән йорт төзүчеләрнең мәгълүматны ачуга һәм урнаштыруга таләпләрне үтәүен тикшерүдә тоту кысаларында үткәрелгән чаралар саны | |
| 23. | 214-ФЗ номерлы Федераль законның $23^3$ статьясындагы 5 өлеш нигезендә торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылган документлар саны | |
| 24. | Йорт төзүче эшчәнлеген тикшерүләр үткәрү турында мәгълүматны, Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалануы чикләнгән белешмәләрдән тыш, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында урнаштыру саны, шулай ук 214-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен һәм законнарда билгеләнгән бүтән таләпләрне бозган өчен йорт төзүчене, аның вазыйфаи затларын административ җаваплылыкка тарту турында законлы көченә кергән карарлар турында белешмәләрне урнаштыру | |

Җирле үзидарә органнары тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисапка кушымта

Форма

Өлешле төзелештә катнашучылар акчасын җәлеп итеп,
муниципаль берәмлек территориясендә төзелә торган
объектлар турында мәгълүматлар

_____________________________________________________________

(муниципаль берәмлек исеме)

______ елның_______ кварталы

| Т/с | Йорт төзүченең тулы (фирма) һәм кыскартылган исеме, урнашу урыны, ИНН, йорт төзүченең рәсми сайты | Күчемсез милек объекты исеме (функциональ билгеләнеше, катлар саны), күчемсез милек объектының урнашу урыны (төзелеш адресы), төзелешкә рөхсәт турында мәгълүмат (№, бирелгән көн, кем биргән, гамәлдә булу вакыты), объектны кулланылышка кертүгә рөхсәт алуның планлаштырылган вакыты | Объектның гомуми мәйданы, шул исәптән торак | Төзелешнең планлаштырылган бәясе, млн.сум | Төзелеш проектын тормышка ашыруның якынча графигын саклау: (саклана/сакланмый) | Төзелеш өчен бирелгән җир кишәрлегенә теркәлгән милек/аренда хокукы турныда мәгълүмат (дәүләт теркәве номеры, теркәү көне) | Күчемсез милек объекты составында өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре төзелергә мөмкин булган мөстәкыйль өлешләрнең гомуми саны | | | Күчемсез милек объекты буенча өлешле төзелештә катнашу шартнамәсе төзегәннәр турында мәгълүмат | | | Өлешле төзелеш объектларын өлешле төзелештә катнашучыларга тапшыру вакыты | | Объектны кулланылышка кертүгә рөхсәт турында мәгълүмат (№, бирү көне, кем биргән) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | фатир | торак булмаган бүлмәләр | машина урыны | беренче шартнамәне теркәү көне | төзелеш башланганнан соң төзелгән шартнамәләрнең гомуми саны | шартнамәләр буенча йөкләмәләрнең гомуми суммасы (млн.сум) | шартнамәләрдә каралган | үзгәртелгән (өстәмә килешү белән күздә тотылган) | |

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 19 апрель, 268 нче
карары белән расланды

Форма

Җирле үзидарә органнары тарафыннан торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы
хисап

_________________________
(муниципаль берәмлек исеме)
_______елның ______ кварталы

| Т\с | Күрсәткеч | Хисап мәгълүматы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Муниципаль берәмлек территориясендә торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан төзелә (төзи) торган күпфатирлы йортлар саны | |
| 2. | Закон бозулар ачыкланган күпфатирлы йортлар саны | |
| 3. | Муниципаль берәмлек территориясендә торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан төзелә торган күпфатирлы йортлар турында мәгълүматлар | әлеге хисапка кушымта нигезендә |
| 4. | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән мондый кооперативның кооператив әгъзалары һәм бүтән затлар алдындагы үз йөкләмәләрен үтәүе турында хисап формасын һәм әлеге хисапны торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыручы органына тапшыру тәртибен раслау хакында» 2017 ел, 3 июль, 955/б номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча үз вакытында квартал хисабын тапшырган торак-төзелеш кооперативлары саны | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 5. | Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Торак-төзелеш кооперативының торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында, шул исәптән мондый кооперативның кооператив әгъзалары һәм бүтән затлар алдындагы үз йөкләмәләрен үтәүе турында хисап формасын һәм әлеге хисапны торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзелеш өлкәсендә дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыручы органына тапшыру тәртибен раслау хакында» 2017 ел, 3 июль, 955/б номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча үз вакытында квартал хисабын тапшырмаган торак-төзелеш кооперативлары саны | |
| 6. | Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күпфатирлы йорт төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп иткән торак-төзелеш кооперативлары саны | |
| 7. | Суд карары белән бөлгенлеккә төшкән (банкрот) дип танылган торак-төзелеш кооперативлары саны | |
| 8. | Россия Федерациясе Торак кодесының (алга таба – РФ ТК) 110 статьясындагы 3 өлеш белән каралган мәҗбүри таләпләрне билгеле булган бозулар саны, күпфатирлы йортларны алга таба карап тотудан һәм РФ ТК $123^1$ статьясыннан тыш | |
| 9. | Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан РФ ТК 110 статьясындагы 3 өлеш белән каралган мәҗбүри таләпләр бозылу белән бәйле мөрәҗәгатьләр саны, күпфатирлы йортларны алга таба карап тотудан һәм РФ ТК $123^1$ статьясыннан тыш, шул исәптән:<br>гражданнардан;<br>юридик затлардан | |
| 10. | Торак-төзелеш кооперативлары әгъзаларының законлы мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклый торган гаризалар белән җирле үзидарә органнары судка керткән мөрәҗәгатьләр саны | |
| 11. | Торак-төзелеш кооперативлары әгъзалары файдасына канәгатьләндерелгән дәгъвалар саны | |
| 12. | Федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган бүтән Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләрне бозуның җинаять җаваплылыгына тартыла торган гамәл билгеләре булган фактлары ачыклану белән бәйле хокук саклау органнарына җибәрелгән материаллар саны | |
| 13. | Җинаять эше кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен мәҗбүри таләпләрне бозуның җинаять җаваплылыгына тартыла торган гамәл билгеләре булган фактлары ачыклану белән бәйле җирле үзидарә органнары җибәргән материаллар буенча хокук саклау органнары кузгаткан җинаять эшләре саны | |
| 14. | Җирле үзидарә органы тарафыннан торак-төзелеш кооперативларының идарә органнарына җибәрелгән закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләр саны | |
| 15. | Җирле үзидарә органы тарафыннан торак-төзелеш кооперативларының идарә органнарына җибәрелгән закон бозуларны бетерү турындагы үтәлгән күрсәтмәләр саны | |
| 16. | Законнар белән билгеләнгән җаваплылыкка тартылган торак-төзелеш кооперативлары (аларның вазыйфаи затлары) саны | |
| 17. | Торак-төзелеш кооперативларының яңа әгъзалар җәлеп итү буенча эшчәнлеген торак-төзелеш кооперативы тиешле бозуларны бетергәнгә кадәр туктатып тору турында бирелгән күрсәтмәләр саны | |
| 18. | Җирле үзидарә органы күрсәтмәсен үтәмәгән очракта, җирле үзидарә органнары тарафыннан арбитраж судка йорт төзүче оешманы бетерү турындагы гариза белән мөрәҗәгать итү саны | |
| 19. | Торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген тикшерүләр үткәрү турында мәгълүматны, Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалануы чикләнгән белешмәләрдән тыш, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында урнаштыру саны, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодесы таләпләрен һәм законнарда билгеләнгән бүтән таләпләрне бозган өчен йорт төзүчене, аның вазыйфаи затларын административ җаваплылыкка тарту турында законлы көченә кергән карарлар турында белешмәләрне урнаштыру | |

___

Җирле үзидарә органнары тарафыннан торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисапка кушымта

Форма

Торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан
муниципаль берәмлек территориясендә төзелә торган
объектлар турында мәгълүматлар

______________________________________________

(муниципаль берәмлек исеме)

______ елның______ кварталы

| Т\с | Торак-төзелеш кооперативының тулы (фирма) һәм кыскартылган исеме, урнашу урыны, ИНН | Күчемсез милек объекты исеме (функциональ билгеләнеше, катлар саны), төзелешкә рөхсәт турында мәгълүмат (№, бирелгән көн, кем биргән, гамәлдә булу вакыты), объектны кулланылышка кертүгә рөхсәт алуның планлаштырылган вакыты. Гамәлгә кертүгә рөхсәт реквизитлары (андыйны алган очракта) | Җир кишәрлегенә хокуклар турында мәгълүмат: хокук билгеләүче документ исеме һәм реквизитлары; милекче турында мәгълүматлар (торак-төзелеш кооперативы җир кишәрлегенең милекчесе булмаган очракта); кадастр саны; мәйданы, кв.метр | Төзелә торган күпфатирлы йорт составындагы, шартнамәләр төзелү мөмкинлеге булган торак бүлмәләрнең гомуми саны | Төзелә торган күпфатирлы йорт составындагы, шартнамәләр төзелгән торак бүлмәләр турында мәгълүмат: беренче шартнамәне төзү көне; төзелеш башланганнан бирле төзелгән шартнамәләрнең гомуми саны; хисап чорында төзелгән шартнамәләр саны; хисап чорында өзелгән шартнамәләр саны; шартнамәләр буенча йөкләмәләрнең гомуми суммасы, млн.сум | Төзелә торган күпфатирлы йорт составындагы торак бүлмәләрне шартнамәләр буенча куллануга тапшыру вакыты | Торак-төзелеш кооперативы тарафыннан шартнамәләрне үтәү турында мәгълүмат: үтәлгән шартнамәләр саны; үтәлмәгән шартнамәләр саны; шартнамәләр буенча үтәлмәгән йөкләмәләрнең гомуми суммасы, млн.сум | Төзелеш проектын тормышка ашыруның якынча графигын үтәү: (үтәлә/үтәлми) | Объектны кулланылышка кертүгә рөхсәт турында мәгълүмат (№, бирү көне, кем биргән) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | |